ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

31.10.2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Текмәле авылында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Текмәле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"17.10.2025 ел, № 5 карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Текмәле авылы гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1.2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту).

3.Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51нче йорт; Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Текмәле авылы, Ишкәй ур., 15 нче йорт адреслары буенча Үчәлле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Азнакай муниципаль

районының рәсми сайтында http://aznakaevo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М. Төхвәтуллина